РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Сухаревского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Сухрау авыл жирлеге
Башкарма комитеты

423559, Нижнекамский район,
с. Сухарево, ул.Пролетарская, 12

423559, Түбән Кама районы,
Сухрау авылы, Пролетар урамы, 12

тел./факс (8555) 44-11-44, электронный адрес: Suharevskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www.suharevskoe-sp.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

05.07.2022ел

№ 18

Сухрау авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 27 мартында кабул ителгән 12 номерлы карары белән расланган Сухрау авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә, Сухрау авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Сухрау авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 27 мартында кабул ителгән 12 номерлы карары белән расланган Сухрау авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктта «, муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

12 пунктта:

икенче абзацта «, муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 еллык чорда ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламалардан файдалану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр саны яки түләүчеләрнең гомуми саны белән нисбәттә характерлана торган күрсәтелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Р.Р. Галимов